Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

2019 нчы елның 13 нче апреле — № 16

**КАРАР** — **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының
2017 елның 15 мартында кабул ителгән
3 нче номерлы “Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү
өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү
Административ регламентын раслау турында” карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 2019 елның 3 нче апрелендә чыгарылган 02-08-02-54-2019 нчы номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 15 мартында кабул ителгән 3 нче номерлы карары белән расланган “Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктча белән тулыландырырга:

“10) Гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматларның юклыгы яки төгәлсезлеге беренче тапкыр документларны кабул иткәндә күрсәтелмәгәндә, яисә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пункты белән каралган очраклардан тыш, документлар яки мәгълүматлар таләп итү. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судсыз) күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләрен(гамәл кылмавын) шикаять итү, мөмкин шул очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителүче күпфункцияле үзәккә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса.

2. 5.8 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Гаризаны карау яки караганнан соң барлыкка килгән нәтиҗәләр буенча административ хокук бозу яки җинаять очрагы расланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле хезмәткәр яки вазыйфаи зат “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 11.2 статьясы 1 бүлегенә туры китереп, булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә”.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үзем артыннан калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов